СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**2019 ел «14» март** **№ 236**

**Арча район Советының 2018 елның 13 октябрендәге 202 нче номерлы карары белән расланган һөнәри (вазыйфаи) бурычларны үтәүне тәэмин итү һәм каршылыклы мөнәсәбәтләрне җайлау буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

Арча район Советы карар бирә:

1. Кадрлар алышыну сәбәпле һөнәри (вазыйфаи) бурычларны үтәүне тәэмин итү һәм каршылыклы мөнәсәбәтләрне җайлау буенча комиссия эшчәнлеген оештыруны камилләштерү максатында Арча район Советының 2018 елның 13 октябрендәге 202 нче номерлы карары белән расланган һөнәри (вазыйфаи) бурычларны үтәүне тәэмин итү һәм каршылыклы мөнәсәбәтләрне җайлау буенча комиссия составына үзгәрешләр кертергә һәм кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Бу карар аны рәсми рәвештә бастырган көннән үз көченә керә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ф.Гариповага йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ
ИНН 1609009523

Арча район Советының
2019 елның «  » ___________
_____ номерлы Карарына
Кушымта

**Һөнәри (вазыйфаи) бурычларны үтәүне тәэмин итү һәм каршылыклы мөнәсәбәтләрне җайлау буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Гарипова Гөлнара Фидәил кызы | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Гапдерахманова Гүзәл Әдһәм кызы | - Арча район Советы оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары; |
| Фәйзрахманова Эльвира Минзаһит кызы | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесе, комиссия сәркатибе. |
| *Комиссия вәкилләре:* | |
| Зарипов Рөстәм Зөфәр улы | «Г.Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном профессиональ белем бирү учреждениесы физик тәрбия укытучысы (килешү буенча); |
| Габдрахманов Наил Газиз улы | - Арча районы ветераннар (пенсионерлар) җәмәгать оешмасы Идарәсе рәисе (килешү буенча); |
| Насыйбуллин Исрафил Рәхмәтулла улы | - «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Арча-информ» филиалы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Мөхәммәтова Алсу Фирдәүс кызы | - Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр буенча бүлек җитәкчесе; |
| Таһиров Айнур Мулланур улы | - Арча муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе; |
| Харисов Вакыйф Вәгыйз улы | - Арча районы профсоюз оешмалары координацион Советы рәисе (килешү буенча); |
| Һидиятов Ринат Әлифхан улы | - «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясе Арча җирле бүлекчәсенең баш белгече, Арча муниципаль районы Җәмәгать советы рәисе (килешү буенча). |